**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Советы Карары**

Олы Әтнә авылы 25 февраль 2021 ел

№ 20

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.19 ел, № 126 карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Олы Әтнә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ.:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 126 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү:

1.1. Нигезләмәнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:
- инициативалы проектларны тәкъдим итү , әзерләү ,сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә »;
1.2. 3. 20 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:
« Әгәр гражданин җитди сәбәпләр ( сәламәтлек ,инвалидлык һ. б.) буенча гражданнар җыенында катнаша алмаса, гражданинның фамилиясе ,исеме һәм атасының исеме , аның яшәү урыны , аның гражданнар җыенында катнаша алмавы сәбәбе , шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте аның гаризасы нигезендә гражданнар җыенында исәпкә алына».
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Хакимов